Айдар **Җамал**

# КҮКРӘГЕМДӘ — КҮКЛӘР...

**Шигырьләр**

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2008

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5
Җ17

**Җамал А.М.**

Күкрәгемдә — күкләр...: шигырьләр / Айдар Җамал. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. — 95 б. — 2000 д. — ISBN 978-5-298-01705-3

Яшь шагыйрь Айдар Җамалның беренче китабына аның лирик-фәлсәфи шигырьләре тупланды.

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5
© Татарстан китап нәшрияты, 2008
© Җамал А.М., 2008

## АБЫНУ ЛӘЗЗӘТЕ

Әдәбият галимнәре шагыйрьләрне буыннарга бүләргә ярата. Шигъриятне күзаллау өчен җайлы алым, әлбәттә. Беренче карашка үзен аклый да: чыннан да, гадәттә, шагыйрьләр әдәбият мәйданына төркем-төркем булып килә бит. Заманында, Фәйзуллиннар буыны, дип шау килделәр. Иҗатларының башында — алтмышынчы елларның уртасында — әлеге төркем монолит булып күз алдына килә иде. Ләкин тора-бара бу шагыйрьләрнең һәммәсе үзенчәлекле, бер-берсенә охшамаган каләм ияләре булып җитлекте. Һәм аларның иҗатын һич кенә дә бер уртак бизмән белән үлчәргә мөмкин түгел.

Шагыйрьләрнең һәрберсе үзгә бер дөнья. Шулай булмаса, аларның үзләре дә, иҗатлары да беркемгә кирәк булмас иде.

Хәер, шагыйрьләрнең генәме... теләсә кемнең күңеле үзгә бер галәм... әмма шундагы тетрәнүләрне, йолдыз җилләрен, тып-тын зилзиләләрне кәгазьгә төшерү — шагыйрьләр өлеше.

Шагыйрьне гауваска да охшатып була. Ул да энҗе-мәрҗәннәр эзләп күңел диңгезенә даими чума бит!

> Шаулый-дулый Тын океан
> Кечкенә кешенең төпсез җанында, —

дип яза Айдар Җамал.

Җанның төпсезлеге, күңел биеклеге кешене шагыйрь итәдер, мөгаен.

Татар шигъриятенә яңа буын килә, дип өн салдылар. Йолдыз Миңнуллина, Ленар Шәех, Рифат Сәлах, Лилия Гыйбадуллина... Исемлекне тагын да дәвам итеп буладыр. Айдар Җамал да шулар рәтендә... Әлбәттә, яшьләре бер чама икән, аларның язган нәрсәләрендә дә охшаш аһәңнәр булмыйча калмас. Бер мохиттә яшәп, бер суны эчкән замандашлар өчен табигый хәл. Ләкин бүгеннән үк әйтеп була: әлеге яшьләрнең һәрберсе үзенчәлекле, аларның фикер йөртү рәвеше төрле, шигырь тукымасы да һәрберсенең үз ысулы белән тукылган.

Айдар Җамал, миңа калса, алар арасында иң нык аерылып торганы. Аның шигъри культурасы яшьтәшләренекенә бөтенләй охшамаган. Мондый үзгәлек Айдарның шәһәр егете булуыннан да

киләдер. Татар теленең шәһәр мохитендәге әверелешләре нәкъ шул килеш аның язмаларына кереп китә.

Шәһәрдә туган кешегә үз теленең сафлыгын, табигый агышын саклау шулкадәр дә авыр. Даими урыс мохитендә яшәү шагыйрьне үз ватанында рухи мөһаҗиргә әверелдерә. Әлбәттә, Айдар өйдә чын татар тәрбиясен алган, туганнарына кайтканда, авыл тормышында кайнашкан (табигать тәэсире шагыйрь өчен бик мөһим), университетның татар бүлегендә укыган — шуңа да аны телнең хасиятен белмәүдә гаепләү дөрес булмас иде. Әверелешләрне бер генә сәбәп белән аңлатып була — хасият үзе үзгәрә бара!

Көтелмәгән сүзтезмәләр (калька түгел!), гайре табигый тоелган җөмлә төзелеше... сискәндерә, ризасызлык уята. Һәм елмаеп куясың — син авторның текстына битараф түгел, язганы күңел кылларына кагыла. Шигырь, нинди булуына карамастан, битараф калдырмаска тиеш.

Айдарның текстларында гади генә нәрсәләр турында сүз бара, гади генә күренештән дә ул үзенчә мәгънә таба белә. Менә бөтенебез кичергән җавапсыз мәхәббәтнең ул бөтенләй бүтән ягын ачып биргән:

Мин сине кыш көне
Яраттым.
Кагылып эретермен дип
Курыктым.
Мин сине җәй көне
Яраттым.
Кагылып, җанны
Өшетермен дип курыктым.

Юк, бу җавапсыз мәхәббәт түгел, тигезсез мәхәббәт фаҗигасе, мөгаен.

Айдарның шигырьләрендә ялган пафос юк. Югыйсә бу чир белән яшь шагыйрьләр еш авырый. Кайберәүләрдә ул гомерлеккә кала.

Айдар примитивизмнан да курыкмый, кайчакта аның шигырьләрендә пародия төсмерләре дә өстенлек итә. Кафия, вәзен мәсьәләсендә дә ул талымсыз — еш кына аның язганнары верлибр жанрына авыша. Әлбәттә, шигърият өчен бу сыйфатларның берсе дә яңалык түгел. Ләкин төче, ялган пафослы тезмәләр шулкадәр туйдырган заманда авторның ихласлыгы күңелне әсир итә.

Айдарның шигырьләрен укыганда, компьютер каршында утыручы япа-ялгыз яшүсмер сурәте күз алдына килә. Дөнья киң, бәлки, матурдыр да, ә кеше — ялгыз.

Ялгызлык! — менә шагыйрьнең бердәнбер сыену урыны.

Ул, билгеле, бу дөньяга Тукайча ят кеше. Дөньядан ул канәгать түгел, дәгъвасы зур, ул аны үзгәртергә тели... яхшы якка... гаделлек ягына...

Шигырьләр яшьлек максимализмы дигән уңдырышлы туфрактан шытып чыга.

Айдар Җамалның шигърияттәге язмышын әлегә фаразлау кыен. Эзләнүчән, тынгысыз җаны кайсы сукмакларга алып керер — бер Алла белә. Ә бүгенге халәтен ул бик төгәл тасвирлап биргән:

Адым саен мәгънә эзләгәндә,
Каты абындым.
Башымны ярган җирдә
Мәгънә калдырдым.

Нишлисең, шагыйрьләр язмышы шундый. Ләкин башны барыбер сакларга кирәк. Ул әле кирәк булыр...

*Ркаил Зәйдулла*

* * *

Адым саен мәгънә эзләгәндә,
Каты абындым.

Башымны ярган җирдә
Мәгънә калдырдым.

## МИНЕМ КҮҢЕЛ

Казан суы шаулый калада,
Көчле җилләр улый далада.
Шаулый, дулый Тын океан
Кечкенә кешенең төпсез җанында.
Тормыш гөрли шаулы калада,
Гөлләр үсә чиксез далада.
Атыла янартау, ялкын бар анда —
Гади генә адәм җанында.

* * *

Монда минем ата-анам,
Мин аларны бик нык яратам.
Монда ята ата-бабаларым,
Күбесенең кабере югалган.
Монда көчле, моңлы татарым,
Күпме гасыр сакланган.
Монда минем таныш-дусларым,
Кирәк чакта юк алар.
Монда яши минем мәхәббәтем!
Монда сагыш... күз яшьләрем.
Монда дәүләт, монда Ватаным,
Ул таркалса, белмим, нишләрмен?
— Юкка чыкмам,
Язмыш елгасында
Тормыш көймәсенең
Ишкәкләрен ялгыз ишәрмен!

* * *

Тормыш — юллар,
Озын юллар, кыска юллар.
Кемгәдер гел такыр алар,
Ләкин бик кыскалар.
Миңа исә ватык, тар сукмаклар.
Кызык тормыш — авыр сынаулар.
...Безнең юллар кисешәләр,
Бәхет-шатлык,
Кайгы-хәсрәт тулы алар.
Юлда һәрчак кирәк дуслар.

Озын юллар озак салыналар,
Кыскалары — йә изгелек белән,
Йә явызлык белән тулганнар...
Юллар, юллар,
Безнең буын сезнең кайсын сайлар?

* * *

Бомбалар шартлый...
Мәскәүдә шартлый,
Нью-Йоркта шартлый,
Багдадта шартлый.
...Йөрәктә шартлый.
Лондонда томан,
Имеш, Блэрларга
Берни күренми.
Күңелдә — төтен,
Башта күк күкри,
Күземдә яңгыр...
Яңгырда туңып,
Мең йөрәк тетри.
Кап-кара яңгыр...
Кемнәрдер хәзер
Мәскәүдә шартлый...
Нью-Йоркта шартлый...
Багдадта шартлый...
Яһүди, христиан,
Будда, мөселман, —
Кешеләр үлә!..
Йөрәгем шартлый!..
Кулымда каләм...
Күңелем бушый.
Мине тыңламый, —
Бомбалар... шартлый.

## ХАЛӘТ

Йөрәк яна!
Тозлы күз яшьләре
Бу ялкынның көчен сүрелтмәс.

* * *

Вакыт туктап тора,
Тирә якта тынлык.
Читтә калып тора сәясәт.
Тынып тора кайгы һәм хәсрәт.

Шундыймы син, якты мәрхәмәт?

## КЫШКЫ МАТУРЛЫК

Урамда карлар ява.
Кар томанында һава
Җаныма тынлык сала.
Тормыш атлы шук бала
Шул мизгелдә туктала.
Һәрчак хәрәкәттә булган
Башкалабыз тын кала...

## БАЛАЧАКНЫ САГЫНУ

Әй балачак,
Әй рәхәт чак,
Ерагаясың һәрчак.
Борчусыз һәм беркатлы чак,
Сагындырасың кайчак.
Елатасың, җырлатасың,
Баш сорау белән тулган чак.
Бервакытны, киләчәктә,
Үз балам да булачак.
Бәлки, шулчак
Иң кадерлем,
Зур бәхетем кайтачак!

* * *

Зилзиләләр,
Кара гарасатлар,
Сугыш —
Үлем, кан коюлар...
Язмыш.
Кеше үзе тапкан язмыш.
Булмас безгә бу язмыштан
Узмыш.

Саба җиле,
Ләйсән яңгырлары.
Сөю, кавышулар,
Бәхет мизгелләре...
Кирәк, шундый кирәк
Безгә язмыш!

## ЮК

Шигырь язылмый,
Илһам да юк.
Өстем бөтен,
Тамагым тук.

Гел елмаям мин,
Шаян һәм шук.
Газап чикмим,
Борчулар юк.

Йөрәк әрнеми,
Яралар юк.
Акчам да бар юкса,
Бәхетем... юк.

## ТАБИГАТЬ БАЛАСЫ

Бүген көне буе
Җылы яңгыр ява,
Кыштан калган
Салкыннарны юа.

Шундый рәхәт миңа,
Йөрәктә боз эри.
Әллә гашыйк булдым?
Күңел хисләр тели.

Матурлыкка гашыйк
Булу — татлы җәфа.
Бүген көне буе
Җылы яңгыр ява...

* * *

*(Виктор Гюго мотивлары)*

Дөреслекнең иге-чиге юк,
Һәм барлык кешеләр
Кеше дигән исем ала.
Тиранлыкның җиңелрәге юк,
Коллык авырлыгы
Җилкәләргә зур йөк сала.

Мин һәр мескен белән
Тоткынлыкта ятам.
Милли көрәш,
Белмим, берәр вакыт бетәрме?

Үзе изелмәгән халык
Башкаларга кылыч күтәрми.

## АККОРД

Күңелсезлек —
Тимерчыбыгына
Кунган чыпчык
Янып төште.
Өметсезлек —
Күктән балкып
Торган йолдыз
Сүнеп төште.
Бәхетсезлек
(Мин теләмәс идем,
Каләмемнән
Бу төшенчә
Үзе төште) —
Җиләк эре,
Кызыл булып,
Өзелер өчен
Пеште.

* * *

Салават күперенә
Сокландым.
Дога күпере бит ул —
Уйландым...

* * *

Кырга чыктык —
Ачы җилләр.
Очып киттек —
Соры чүлләр.

Карап үттек,
Тик торналар
Тик торалар.
Вакыт ага...

## БЕР КЕШЕГӘ

Дөнья бик зур,
Дөнья матур.
Нигә кирәк

Сыктаулар?

Җырлар бик күп,
Күңел моңлы.
Сагышыңны
Өйрән көйләргә.

Кайгы бик күп,
Сагыш сары.
Борчуыңны сөйлә
Җилләргә.

Йөрәгең зур,
Үзең горур.
Нигә кирәк
Ваклану?

## АРЫДЫМ

Матур-матур җырлар җырлар идем —
Тавышым юк.
Классик бер шигырь язар идем —
Талантым юк.
Хәерче-ачларны яклар идем —
Тамагым тук.
Язмышның җепләрен сүтәр идем —
Йомгагым юк.
Бар кешене аклар идем —
Теләгем юк.

* * *

Нәрсә соң ул мәңгелек? —
Аллаһ язган бер мизгел.
Күчсен иде мәңгелектән
Мәңгелеккә хөр күңел.

## АЛАБУГА

Ак мәчет.
Хәрабәләр.
Шайтан каласы.
Нигез ташларына
Кулны куйдым.
Монда килә
Мәңгегә каласы.
Башта күпме

Хатирәләр...
Мин болгарның
Нәни баласы.
Әти сугыш
Кырларында калды,
Әнкәй — намазлыкта.
Явыз яулар,
Шәхес культы...
Тукта!..
Кулны куйдым
Нигез ташларына.
Бу галәмгә
Ничек сыясы?
Моңлы башны
Кая куясы?

* * *

Кош буласым килә,
Алар һава тәмен белә.
Болыт ерасым килә,
Кояш якыннан көлә.
Җил уңаена гына
Канатлар киерелә.
Күк катыннан язмышлар да
Бик җиңел күзәтелә.
Күптән бабам әйткән сүзләр
Кабат башыма килә:
«Күк йөзенә озак карасаң,
Ул сиңа серен сөйләр:
Кош кебек очалмасаң да,
Ирекле тормыш телә!»

## МӘҢГЕЛЕККӘ КҮЧТЕҢ БУ КӨННЕ

*Дәү әтиемә*

Туфрагыңда нәфис гөлләр үскән,
Җаның иркен иде болындай.
Хыялларың оныкларга күчкән,
Кешелеккә мирас булырдай.
Сагынып килдем тынлык дөньясына,
Сөйләр өчен җылы сүзләрне.
Кочтым...
Салкын мәрмәр һәм дә кайнар туфрак.
Истәлекләр юа күзләрне.

* * *

Бөеклеккә дә омтылмыйм,
Биеклеккә дә түгел.
Тирәнлектә агымым,
Фәлсәфәм — күңел.

* * *

Илһамландырмый Казан,
Шигырь дә яздырмый,
Урамга да чыгып булмый
Меңьеллыкны уздырмый.

Кесәләрне актара
Погонлы «зәңгәр күлмәк»,
Нәрсә булсын инде миндә?
Шагыйрь коралы — йөрәк!

* * *

Диңгез диләр —
Пүчтәк икән.
Җитәме соң
Безнең Иделгә!
Таулар диләр —
Ослан әйбәт,
Тәрәзәдән горур
Күренә.
Банан, персик,
Хөрмә диләр.
Вай, аларны
Ашап үләргә.
Минем хыял —
Туган ягым.
Бер алманы
Бишкә бүләргә.

## ЧЕРЕК КҮЛДӘ ЯНГЫН

Матур. Казан өсте
Сыек төтен-томан!
Борчу. Черек күлдә
Тәмуг йорты янган.

* * *

Көрәшми яту
Дөрес микән?

Һәр көн кыйналу
Дәрес микән?

## СУ БЕТКӘН

«Бездә салкын су юк», — дисең,
Ә бездә — кайнар.
Җаннарыбыз саекмасын!
Без — ярлы байлар.

* * *

Кояш инде, имеш —
Илаһи якты инеш.

Сандык иске, имеш —
Эче тулы көмеш.

Кеше әйбәт, имеш —
Үрдән төпкә күчеш.

## ЯШӘҮ ЯМЕ

Шәхси кайгы
Тышка чыкса,
Кеше ишен
Санламаса,
Дөнья чүпкә
Батар иде...
Яшәү яме
Бетәр иде...

Яшәү яме
Бетеп килә.
Кеше булу
Кирәк.
Һәр чат саен
Акыл сатсам,
Шыпырт кына
Сыкрый ярам.

Табигатьтә
Күп нәрсә сер,
Ә төп сынау
Ул бары бер.
Могҗизалар
Тусын өчен
Кирәк түгел

Аңлау көче!

## ҺАМАН КАЗАН

Саумы Казан,
Иҗат башкалабыз.
Чакыруың белән киләмен.

*Ш.Галиев*

Килмимен дә,
Китмимен дә,
Мин — Казанның
Нәни баласы.

Артмыймын да,
Бетмимен дә,
Алда әле
Җырлар язасы.

Янмыймын да,
Сүнмимен дә,
Илем белән
Алга барасы.

Сүгелмәс тә,
Сүрелмәс тә
Шәһәр салган
Шигырь ярасы.

Югалмас та,
Юралмас та
Шигырь биргән
Иҗат шифасы.

## КАРАНТИН

Имансыз дөнья —
Эпидемия.
Китә алмассың
Әллә кая, кош булып та.
Башыңны кисәр
Кош гриппы.
Мышкылдап ятам,
Терелү килми шигырь язып та,
Башыма җитте
Шагыйрь гриппы.

## БУЛМАС, АХРЫ...

Булмас, ахры,

Шигырь язып туеп.
Каләм очы шуа
Кәгазь-боздан таеп.

Җилкәләргә
Дуга салды — җигә,
Шигырь уты сүнми,
Минлегемне җиңә.

Каләм, шума,
Баш әйләнә, тукта!
Йөрәгемдә кара тибә,
Соңгы сүзем — нокта.

## ИР-АТ

«Без, ирләр, шундый затлар инде:
зур куллы һәм нечкә күңелле».

*«Мюнхен» фильмыннан*

* * *

Бездән һәрчак
Көтәләр батырлык
Хәтер такталарын
Тутырырлык,
Хатын-кыз йөрәген
Яндырырлык...

* * *

«Кылыч тотмаганы
Чын ир түгел».
Күпме җанны
Эзәрлекли бу гел.
Тыныч дөнья тели
Олы куллы күңел.

* * *

Соң арада хатын-кызлар
Чаба кабаланып,
Мескенләнгән ир-ат
Кыяфәте алданырлык.
Тик дөньяны саклау өчен
Төп шарт — зур куллылык.

* * *

Йөрәгем кечкенә
Саф инеш.
Бер мизгел, бер күкрәү —

Һәр тибеш.

Тик сабый йокысы —
Ямь, имеш.
Тарлыктан бәхеткә
Хак күчеш.

Акылым төбендә
Фәлсәфә,
Ә җаным агышы —
Зур сәфәр.

Болыннар өстеннән,
Ташлардан...
Балачак бит шуннан
Башланган.

Бәхетле күренгән
Тормыштан
Яланөс йөгерәм
Тумыштан.

Шундыйрак яшәүгә
Юлламам.
Җәйге төн ярала.
Уйланам.

* * *

Яңгыр кешесе түгел мин,
Кояш баласы.
Дөньям яме — җәйге көн —
Шатлык каласы.

* * *

Ачык күзле төннәр
Патшалыгы бу.
Тозлы сулы монда
Чишмәләр.
Адым саен галим, фәлсәфәче
Карашыңнан галәм серен
Чишәләр.

## ЯШЬЛЕК СОРАУЛАРЫННАН

...Әллә уйлыйм инде?
Юк. Зар гына коям.
Ерак күрмим икән,
Биек түгел кыям.

Яшьлек китабымны
Укыгандай итәм.
Дөреслектә
Язмыш муенсасын сүтәм,
Юк-бар, мәгънәсезгә
Чәчәм энҗеләрен.
Тулы сулыш алам,
Кичнең эңгерләрен
Әллә инде уйлыйм?

* * *

Елгалар ярларын җимерә,
Меңьяшәр зур таулар ишелә.
Мәңгелек — бик шартлы фәлсәфә...
Туфрактан үсенте тишелә.

* * *

Кара эчтем,
Каләм карасын,
Ямар өчен
Йөрәк ярасын.

Кара тибә
Саксыз йөрәктә.
Каләм манам
Бик нык кирәктә.

Кара каным —
Шифа бәгырьгә.
Кызыл кара
Тама шигырьгә.

* * *

Хуҗасыз этләр
Һәм мин урамда.
Ялгызлык тозы
Тормыш ярамда.

* * *

Минус утыз.
Йөрәгемдә салкын бушлык.
Борылышлар, җилләр
Казаны.
Уйларымда нейтрино да үтмәс
Кургаш башлык.

Бәгырьләрне өзмәс булды
Мулла азаны.
Космик кышлар басты,
Көтмим шатлык,
Күңел юрганына качтым...
Көтәм азагын.

## ШӘҺӘР БАЛАСЫ МИН

Соры диварлар,
Озын торбалар,
Кышкы җылыда
Сыек, комлы кар.

Пычрак тәрәзләр,
Тимер кәрваннар,
Төтен эчендә
Ямьле яшәү бар.

Үтеп барышлый
Ашап чыгулар,
Буялган чәчле
Кызлар — безнең яр.

Горур чырайлар,
Явыз малайлар,
Фәхеш тулы юл,
Адым саен — бар.

Кыйбла — тукталыш,
Күккә омтылыш.
Шәһре Казанда
Һәрчак яңарыш.

...Яшәү мәгънәсе —
Олы бер ярыш.

* * *

Мин көтмим
Дөньядан мәрхәмәт.
Корычтан
Яралган яшәеш.

Әтигә-әнигә
Мең рәхмәт,
Вакытлы ныгыган
Азау теш.

Йөрәккә мең пот
Чүп ябышкан.
Бәхетем —
Котылу рәхәте.

## СОРЫ БУЫН

Бүген күпме тере мәет
Тулган җиргә,
Тик исәннәр белән алар
Никтер бергә...

*Н.Сафина*

Кайчак,
Битарафлык өреп,
Ялгыз утарымда
Ятканда,
Бәгырькәем
Бушлык тулы
Таш сын булып
Катканда,
Уйлап куям:
Тере мәет
бит без.
Тере мәет без.
Эго алласына
Табынуда үтә
Соры көнебез.

* * *

Шигырьгә күңел ятмый,
Шагыйрьләр бүген көчсез.
Тирәнгә керсә, бата,
Ә шигъри дөнья төпсез.

Күлдәвек булган дәрья,
Саеккан шигырь суы.
Патшасыз калган гаскәр —
Таркалган шигырь явы.

Әз-мәз сызгалыйм әле,
Такмаклар языйм әле,
Башлылар акча көрәсен,
Шигырьдә азыйм әле...

## КӨЗ

Кулымда тәлгәш-тәлгәш
Өлгергән кара миләш.
Матурлык тулы учлар,
Якты дөньяга өләш!

Мин яшим җырлый-җырлый,
Күзләрем — елый-елый.
Ә җаным, бүре актыгы,
Хәтта кояшка улый...

* * *

Иртәләр салкынайды,
Һәм көннәр сорыланды.
Ә яшьлек шәмнәрендә
Кичәләр яраланды,
Яктырды, шатлык уты
Таралдырды.
Ә яшәү чоңгылында
Төтен,
Ул күзне ашый.
Дөнья кебек бербөтен
Таркала, ләкин яшьлек яктылыгы
Белән тулган иркә халәтем.

* * *

Мин ялгыз аучы,
Һөнәрем — сунар.
Салкында яшим —
Йөрәгем кайнар.

Мин бәхет аулыйм,
Тормышым — урман,
Мылтыгым шәпле,
Күп сорап тормам.

Мин ялгыз аучы,
Белгәнем — сунар.
Гаделлек аттым...
Мылтыгым кайнар.

* * *

Мин сине кыш көне
Яраттым.
Кагылып, эретермен дип
Курыктым.
Мин сине җәй көне

Яраттым.
Кагылып, җанны
Өшетермен дип курыктым.

* * *

Мин акылга яшим буйсынып —
Хисләр җиңә.
Мин яратам хискә бирелеп —
Акыл күнә.

Вакыт узды,
Иске кием тузды,
Акылым яңа хисләр тудырды.

* * *

Йолдыз балкый тәрәз артында,
Синең нурлы йөзең каршымда,
Йолдыз кебек балкый,
Тормышымны яктырта,
Яна җанның уртасында...
Тик атылма, йолдызым, атылма.

* * *

Акчарлаклар оча Идел өстендә —
Тарлык, бушлык кеше күңелендә.
Бу тарлыкны сөю хисе киңәйтә.
Яшәвемне саф Мәхәббәт җиңеләйтә.

* * *

Сине күрү белән
Күңел күтәрелә.
Сине телим чиксез
Күккә күтәрергә.
Кояш балкый
безнең йөзләрдә,
Балкыш керә
безнең күзләргә,
Балкып торган
Нурлы күзләрдә
Бу җиһанга
Караш үзгәрә.

## ҖАВАПСЫЗЛЫК КОРБАНЫ

Якты һәм катлаулы, татлы хисләр
фикереңне бутар,

Син — кояшка омтылганда канатларсыз
калган Икар!

* * *

Күңелемдә син уяткан хисләр
Поляр төндә таңнар аттырырлык,
Синең белән бергә булган көннәр
Суык кышны хәтта җылытырлык...

* * *

Мин сине яратам.
Күкләр күкри йөрәктә.
Акылымны югалтам
Акыл шундый кирәктә.
Хисләр ташый күңелдә,
Күкләр сыя минем күкрәккә!..

* * *

Мин ул изге затны
Кабат яраттым,
Иске яраларны
Кабат канаттым.
Кирәк микән кабат ярату,
Яраларны кабат яңарту?
Шулай булсын! Көчле хисне
Акыл җиңә алмый.

## ШИГЪРИ СУРӘТ

Төссез көнне күзне чагылдырып,
Җанны җылытучы кояшым син.
Борынгыдан сокландырган,
Матурлыкның бөек үре булган
Афродитадан да камил син.

* * *

Сагындырасың син —
Йөрәк тулы тозлы моң.
Сөендерәсең син —
Йөрәк тулы татлы моң.
Көендерәсең син —
Күңел тәрәзәсен
Тырный ком.
Төннәр буе сине уйлап,
Кача «тыныч йокы»м.

* * *

Минем хисем
Канны яндыра,
Минем җанны
Ялгыз калдыра.

Минем хисем
Башны катыра,
Бөтен булганымны
Сиңа тапшыра.

Минем хисем
Аңсыз калдыра,
Кайнар йөрәгемне
Икегә яра.

* * *

Көям димен,
Көймим дә инде,
Сөям димен,
Сөймим дә инде,
Назлыйм димен,
Тимим дә инде.
Яратам димен.
Нишләргә?
Белмим дә инде.

Беләм дә мин,
Сөям дә мин,
Көям дә мин,
Тимим генә инде...
Язмышымдыр, бәлки?
Әйтмим дә инде...

* * *

Шигырьләр сәер туа,
Күңел кылларын өзеп.

Вулканда янгын туа,
Ялкынга афәт төреп.

Дөньяда сугыш бара,
Меңәрчә гомер өзеп.

Ә мин сагыш күлендә
Батмыйча йөрим йөзеп.

## ЯҢГЫР

Яңгыр ява.
Яңгыр ява кайнар йөрәккә.
Яңгыр ява. Җанны
Әйләндереп өрәккә.
Яңгыр ява. Дымлы
Һава үтеп керә үзәккә.
Яңгыр ява. Салкынлыгы
Тама салкын өметкә.
Яңгыр ява. Нокта куеп
Олы мәхәббәткә.
Яңгыр ява. Нәни эзләреңне юа,
Синнән миңа калган бүләккә.

## ЯРАТАМ

Әйе, мин моңсу,
Иелгән уйлы баш.
Әйе, ямансу
Минем караш.

Юк, әйтмим
Сине сагындым дип,
Гашыйк булдым,
Кабат кабындым дип.

Әйе, һаман сүнми
Өмет очкыны,
Тынгы бирми
Хисләр дулкыны.

* * *

Төннәр буе йолдызларга
Карап яттым,
Озак-озак серен ачып,
Уйлап бактым.
Уйлый торгач, җирдән торып,
Үземә иң зурын таптым.

## ДӨНЬЯНЫҢ БЕР МАТУРЫНА

Синең елмаюны күрер өчен
Туганмын бу төссез дөньяга.
Кылтык һәм дә нечкә йөз чытуың

Арка белән борган мине
кояш төшеп
Ялтыраган тозлы дәрьяга.

* * *

Сине күреп,
Утка гашыйк
Күбәләктәй булдым.
Якын килгән саен
Соңгы күзәнәккә
Кадәр яндым.

Якты кояш булдың
Төнге күгемдә.
Баллы аваз булдың
Тозсыз телемдә.
Шифалы яз булдың
Салкын күземдә.

* * *

Кояш янә сүнде,
Болыт аны каплап тора.
Җиргә карлар иңде,
Каралыкны аклап тора.

Җаным күккә менде,
Ходай аны саклап тора.
Хис йөрәккә керде,
Акыл аны каплап тора.

* * *

Мин сине шундый яраттым,
Ә син...
Син хисемне үлем җәзасына
Хөкем иттең.
Ичмаса, гильотина да түгел,
Ялгыз ташкапчыкка
Сурәтләрең белән бергә аттың...
Мин сине шундый яраттым...
Һәм Монте-Кристоның язмышына
Дучар булдым.
Хисем сүрелгәнче,
Япа-ялгыз диңгез шавын
Тыңлап таш төрмәдә ятам...

* * *

Төрле тавышлардан да
Тәм табып,
Керле сагышлардан да
Ямь табып,
Яшим җырлап
Ялгызым.
Әллә янам сөеп
Ханбикәне,
Әллә туңам көтеп
Кар кызын?
Җырлар, җырлар,
Моңлы да сез.
Көйләп булмас бит
Язын.
Башны диванага
Салырмын да
Сөярмен гади
Җир кызын.

## ЮКТЫРСЫҢ

Юктыр бу дөньяда мәхәббәт,
Юктыр сөю, юктыр сәгадәт.

Күпме бәреләм,
Күпме сугылам,
Таптыйм буш чатларны.

Күз яшьләре
Һәм хәсрәт —
Сагынсам ул чакларны.

Рәсемнәрдә
          генә күрәм
Якты, җылы якларны.

Мәзәк тормыш барында
Мине кояш якларммы?

## СИН ҺӘМ МИН

Икәү пар күгәрчен булып
Зәңгәр күкне иңләдек.
Самолетлар гөрелдәде,
Аларга сер бирмәдек.

Горур акчарлаклар кебек,

Диңгез шавын тыңладык.
Соңгы йолдыз сүнгәндә дә,
Без серләштек, тынмадык.

Гөлләр булып чәчәк аттык,
Озак яшәп шиңмәдек.
Мең тапкырлар соңга калдык,
Вакыт барын белмәдек.

## АНЫҢ ӨЧЕН

Йолдызлы төннәр
Эзләп мендем
Күкләр түренә
Бәгърем өчен.

Иң шәп энҗеләр
Юллап төштем
Дәрья төбенә
Җаным өчен.

Иң җылы хисләр
Кабыздым
Күңел түрендә
Аның өчен.

## КОЯШКАЕМ

Кояшкаем минем!
Сине кочып назлар идем,
Моңлы көйләр җырлар идем —
Син болында, гөлләр арасында.

Сандугачым минем!
Сине ятып тыңлар идем,
Күңел тулып елар идем —
Син еракта, язлар һавасында.

Мәхәббәтем минем!
Хисләремне җилгә сибәр идем,
Ә ул аны сиңа сөйләр иде —
Тик сагышым ага канда.

Әй, матурым минем!
Яңгыр булып чәчләреңә явар идем,
Тамчы-тамчы иренеңнән тамар идем...
Бул син бары минем янымда!

* * *

Минем сиңа бу мизгелдә әйтер сүзем бар:
Син — янартау, мин — бөртек кар.

Миндә сине көткән сары көзем бар.
Син — бөеклек, ә мин — чүп-чар.

Шулай ук мин дә галәмдә яши бирәм,
Үземчә җыр язам, елыйм-көләм.

Күбәләкләр булып төшләреңә керәм,
Иң яшерен серләреңне беләм.

Минем сиңа бу мизгелдә әйтер сүзем бар:
Син — янартау, мин — бөртек кар.

* * *

Һәр секундын тоеп яшим мин тормышның,
Һәр минутын кичәм газапта,
Янартаулар җитмәс мине җылытырга.
Төн. Ай. Казан. Син — еракта.

## ИҢ ЗУР СЕР

Иң зур серләрнең
Берсе — мәхәббәттер,
Дәшми калудан күңелдә
Туган һәлакәттер,
Карашлардан үткән
Очкыннар, хәрәкәттер,
Ерак диңгездәге утрау,
Хөр мәмләкәттер.

## ҮЗЕҢ КИРӘК

Моңсу гына эндәшмиләр
Сагыш тулы күзләрең.
Хәлем бик аяныч икән,
Шигырь язмый түзмәдем.
Серле елмаюларыңнан
Төрле ымнар эзләдем,
Суда гына янмыйча,
Утта гына йөзмәдем.
Чын күңелдән яратырга
Үзең мине өйрәттең.

Матур итеп карап тора
Уйчан фотосурәтең.

* * *

Чыгып киттең
Атлап бусагамнан.
Тамагымда төер,
Артык сусаганнан?

Бәреп киттең,
Ватып ишегемне.
Никтер салкын,
Әллә өшедемме?

Талап киттең,
Алып йөрәгемне.
Мин — бәгырьсез,
Әллә белмәдеңме?

* * *

Диңгез идең,
Тозлы суларыңны эчтем.
Дулкын итеп
Йомшак ярларыңа чәчтең.
Кораб кебек,
Чиксезлекне кичтем.
Син — диңгезем, шавым,
Кырыс табигатем — көчем.

* * *

Икебез дә ут йотабыз:
Син — назлырак,
Ә мин тирән итеп сулыш алам.
Күк йөзеннән ак йолдызлар тотабыз:
Син — батыррак,
Мин янә дәшмичә калам.
Без икебез дә яратабыз:
Син — матуррак,
Ә мин бәхет орлыгыннан яралам.

* * *

Күк болыны тузганагы
Орлыкларын чәчкән
Кышкы төн.
Тузганаклар биеп төшә,

Уйларында төрле көйләр.
Көрт тынлыгы йотып бара,
Җырлар сүнеп бара,
Дөнья — бербөтен.
Ә күкләрдә җырлар... җырлар...
Сизәм, анда гөрли җәйләр!

Тәрәзәңдә яна утлар,
Кыймый торам, керим микән?
Күңлем нидер сизенгәндәй...
Уй-сереңне белим микән?
Мин гаепле, йөрәгеңә
Таш бастырдым.
Шомландыра, уйландыра
Күкрәгемдә яткан көрт-тынлык...

* * *

Үптермисең, киптерәсең,
Яндырасың ирнемне.
Сүз бирмисең, җибәрмисең
Һәм кысасың иркемне.

Бер кочмыйсың, очыртмыйсың
Канатланган йөрәкне.
Бик иркә һәм бик матурсың,
Тик бирәсең кирәкне.

Инде нишлим? Яратам бит,
Җыйдым булган көчемне.
Каләм очында ут яна,
Сүзгә түктем хисемне.

* * *

Синең җаннарыңда борчу булса,
Минем йөрәк дөрләп кабына.
Әгәр юлларыңда киртә торса,
Минем аяк барып абына.
Күзләреңдә шатлык балкыганда,
Җылы керә йөрәк түренә.
Иреннәрең ихлас елмайганда,
Киләчәгем якты күренә.

* * *

Сагына белмим икән бит, —
Юктыр сагыну.

Аңламыйм, көтә белмәгәч,
Ни ул юксыну?
Язмаган, күрәсең, миңа
Мәңгелек яну.
Ерактан гына сары ул —
Төссез бит сагыш.
Кояшка бер таш ыргыттым.
Һәм... ваттым ялгыш.

* * *

Туңга әйләндереп китте
Йөрәгемне бер Кар кызы.
Шуннан бирле дөрләтми,
Гөрләтми каты бозы.
Учында утлар ягып,
Үз ялкыныннан кызып,
Эретә йөрәгемне
Нәни генә Җир кызы.

* * *

Мин сине эзләдем даладан,
Чүлләрдән, күлләрдән, һавадан.

Син диеп казандым чиксез дан.
Колакта шаукымы: даң, даң, даң.

Атылдым ук булып үрләргә,
Кермичә калмадым гүрләргә.

Мин әзер кояшсыз түзәргә,
Тик сине янымда сизәргә.

. . . . . . . . . . . . . . . . . .
Мең яшәрмен мин бер сөеп,
«Бары син, гомергә син», — диеп.

## ЯЗ КОЧАГЫ

Кояш-хәнҗәр
Сызып үтте
Боз капламын.

Яз һавасын
Мул сулады
Җир катламы.

Яшеллекне! —
Җәй буена... —
Май баласы!

Бер кочак яз
Сиңа бүләккә —
Җырлап аласы.

Зур теләгем:
Бу оҗмахта
Бергә каласы.

## САФЛЫК

Мең төрле гөл үсә
Тормыш аланында.
Кайсын ямьсез диим?
Гүзәл һәрберсе.

Күңелемә ятышлысы
Бик күп булыр,
Әйләндерер башны
Хуш исе.

Ә йөрәктә яралганы
Бары берәү генә.
Саф мәхәббәт диеп
Куштым аңа исем.

## АЛДАНМАГЫЗ ЯЗГА

Яздан атлап
Бара идем,
Кинәт буран
Башланды.

Әллә ничек,
Сәер быел,
Әйләндерә башларны.

Әйләндереп
Калса икән,
Күзгә тула
Кар-яңгыр.

Алданып
Кайтып киттем мин.
Мөгаен, ялганчы

Яздыр.

Быел, язым,
Уйлап торма,
Гыйшык дәфтәреңнән
Сыздыр.

Моңа сәбәп
Былтыргы яз,
Мине көткән
Кыздыр.

## ЙӨРӘГЕМ...

Миңа чәчәкләрнең кызыллары якын шул,
Син үстергән ап-аклары да бик матур.

Ак, пакьлеккә гамьсез карам йогадыр,
Кара йөрәгемне сафлык бер яңартыр.

Бик кечкенә булса да, кайдадыр хаклык яши,
Күңелемдә яткан таш катламын ватыр.

Тик яктыга чыксам югалырмын сыман,
Җилләр алса күккә, кем туктатыр?

«Мин саклармын сине!» — диде кебек гөлең —
Таш ватылды. Бер кызара дөньям, бер агара.

Җилләр мине, төндә йолдыз итеп атыр өчен,
Күкләр хөкеменә алып бара.

* * *

Күкләрдән ялварып сорадым:
«Мәхәббәт бирегез, мәхәббәт!»
Җавапка тик сәер фал алдым,
Яшенле, яңгырлы хәрәкәт.

Яшеннән көч, егәр сорадым,
Яңгырдан чисталык һәм сафлык.
Соңыннан бик каты үкендем:
Югалган кадерле тынычлык.

* * *

Зәңгәр хыял
Тулпарына мин атланып
Очып узам болытларны,

Дулкынланып.
Үтәм икән читләп
Бәхетемнең йөзен,
Әллә йөрәгемә язылмаган
«Сөю» сүзе?
...Артык җилле була икән
Тулпар сырты.
Җиргә төшәм:
Ачы бәхет, сынау йорты.
Эзләр калмас сары комда,
Җилләр юар аны,
Ни кузгата икән
Канатланган кеше җанын?

* * *

Күрәсем килә
Кошларның күчешен,
Дәрьялар төбенә
Кояшның үтешен,
Галәмнәр түрендә
Йолдызлар йөрешен.

Тоясым килә
Хисләрнең көрәшен,
Карашың үрендә
Очкыннар биешен,
Күкрәгем эчендә
Йөрәгең тибешен.

Биклисе килә
Ялгызлык капкасын,
Ачасы килә
Бәхетнең япмасын,
Саласы килә
Мәхәббәт басмасын.

## КӨЗ ЯМЕ

Җирдә яфраклы,
Күктә болытлы,
Биләп офыкны,
Көз җитте.

Төрле холыклы,
Ике Болаклы,
Горур халыкны
Сүз басты.

Сулыш кабарып,
Салкын һаваны,
Җилләр кубарып
Мәл йотты.

Төшләр зәп-зәңгәр
Өскә ашкынып,
Йөрәк ташкынын
Төптән кубарыр
Көз-кыз җитте!

* * *

Ярым уяу,
Ярым йокы хәлдә
Төштә күрдем
Сине көзге мәлдә.

Эретерлек назлы
Синең караш төштә генә,
Сызгаламам башка
Кара белән түшәгемә.

Төштән чыкмый
Яшәү безнең язмыш түгел.
Йокысыз төн,
Дулкынланган йөрәк, чиста күңел...

* * *

Бәхетем канат кагына,
Чү, сак кына! Сак кына...
Күтәрелмәсен җилдән
борчу тузаны...
Күкрәктә янгын кабына!

* * *

«Мин яратам» дию
Тик буш сүзләр кебек
Сиңа үз хисемне ачканда,
Киң галәмнәр
Сине сөюемнең
Күзәнәкләренә качканда.

Хисем — дөнья,
Хисем — яшәү,
Өн югала сине кочканда.

## НИК?

Ник бирмисең син миңа
Күңелем теләгәнне?
Ник белмисең сагыштан
Тончыгып үлгәнемне?

Ник кире кагасың
Мәхәббәт бүләгемне?
Ник бирмисең үбәргә
Сөйкемле йөрәгеңне?

* * *

Карашыңнан челтер чишмә ташый,
Тынычланып китә йөрәгем.

Уй гаскәрен тавышың әсир итә,
Горур тоткын булу — чиксез теләгем.

* * *

Шырпы булып кабынам да
Яндырам йөрәкләрне.
Күмергә калып сүреләм
Дөрләргә кирәк мәлне.

Назга сусаган йөрәк мин,
Чишмәдә шомарган таш.
Мине аңламассыз, бәлки,
Яшьлегем йөрәккә баш.

Шырпы булып кабынам да
Яндырам йөрәкләрне.
Саклыйсы иде учактай
Мәхәббәт дигән мәлне.

* * *

> Хәерлегә булсын, хәерлегә:
> Гөлләремә гүзәл төш керде!..
>
> *Зөлфәт*

Тәрәзләргә иртән салкын кояш керде,
Җитешмәдем күкне пәрдәләргә.

Агымсулар көне буе туктап торды.
Хәерлегә булсын, берүк хәерлегә!

Җир шарымда бер континент батты,
Былбыл иле иде — якты истәлек!

Башланмыйча калган тәмам мәхәббәттән
Гөлләр калды тәмләп иснәрлек.

Җәйге күлмәк киеп, кысыр кышка калгач,
Туры килер, туңып, язны көтәргә.

Ә күзләрне һаман салкын кояш чагылдыра,
Хәерлегә булсын, берүк хәерлегә!

## ГАШЫЙКЛАР КӨНЕ

Чыкмыйм урамга,
Нишлисең парсыз?
Бик кыен икән
Бу көндә ялгыз.

Яшерен хисләр
Парадка чыга.
Ялгыз йөрәкләр
Яна борчуда.

Нишләтер безне
Көнбатыш ашы?
Йөрәк канында
Азгынлык башы.

* * *

Мәхәббәт карага буялган,
Йөрәккә мөһерләр куелган.
Әй, акыл, син бөек, син даһи,
Үтерәсең мине, билләһи.

Беркатлы күңелем ашкына
Көчлегә, кайнарга — ташкынга.
Акылым, син кайда шул вакыт?
Саксызны калмыйсың туктатып...

Сазымның кыллары өзелә,
Йөрәккә зинданнар төзелә.
Ташларга бәрелә саф хисем...
Суытма син мине, Гөлдерсен!

Хәнҗәрләр кадасаң, төзәлә,

Богаулап җәзала — түзелә,
Каты сүз гөлгә дә ярамый...
Өзелгән кылларым ялганмый.

* * *

Яңгыр сиңа
Сагышымны сөйләрме?
Дулкын күңел
Җырларымны көйләрме?

Мин табигать кебек
Даһи булалмам,
Йөрәгем — чиксезлек,
Барсаң юлымнан.

* * *

Дөньяда мәхәббәт
Бар микән?
Дөньяда мәхәббәт
Бар икән!
...Мин сине бер
күргәч инандым.

## БӘХЕТСЕЗ БӘХЕТЛЕ

Без ике
Бәхетсез бәхетле!
Үзебез
Өметсез өметле...

Җилкәнен киергән
Көймәбез,
Болытлар дулкынын
Гизәбез.

Давыллар
Рухларны ныгыта.
Йолдызлар
Җаннарны юата.

Сәяхәт —
Илаһи күкләрдә,
Безнең юл
Бирелми күпләргә.

Мәхәббәт утравын

Төплибез...
Йөрәкле яшәеш
Телибез!

## БӘХЕТ ЙОЛДЫЗЫНДА

Мин кояшка чыра гына суздым,
Дөрләп китте йөрәк-учагым.
Мин һавага ялкын булып аштым,
Галәмнәрне иңли күкле кочагым.
Тик сыйдыра бары сине генә,
жаным...
Бәхет йолдызында сине
кочып торган чагым.

## ЭЧТӘЛЕК


Абыну ләззәте *Р.Зәйдулла* .................

**Адым саен мәгънә эзләгәндә...**

«Адым саен мәгънә эзләгәндә...» .............
Минем күңел ..........................
«Монда минем ата-анам...» .................
«Тормыш — юллар...» ....................
«Бомбалар шартлый...» ....................
Халәт ................................
«Вакыт туктап тора...» ....................
Кышкы матурлык ........................
Балачакны сагыну .......................
«Зилзиләләр...» .........................
Юк .................................
Табигать баласы .........................
«Дөреслекнең иге-чиге юк...» ...............
Аккорд ...............................
«Салават күперенә...» .....................
«Кырга чыктык...» .......................
Бер кешегә ............................
Арыдым ..............................
«Нәрсә соң ул мәңгелек?..» .................
Алабуга ..............................
«Кош буласым килә...» ....................
Мәңгелеккә күчтең бу көнне ................
«Бөеклеккә дә омтылмыйм...» ................
«Илһамландырмый Казан...» ................
«Диңгез диләр...» .......................
Черек күлдә янгын .......................
«Көрәшми яту...» .......................
Су беткән ............................
«Кояш инде, имеш...» .....................
Яшәү яме ............................
Һаман Казан ...........................
Карантин .............................
Булмас, ахры... ..........................

Ир-ат ................................
«Йөрәгем кечкенә...» .....................
«Яңгыр кешесе түгел мин...» ................
«Ачык күзле төннәр...» ....................
Яшьлек сорауларыннан ....................
«Елгалар ярларын җимерә...» ................
«Кара эчтем...» .........................
«Хуҗасыз этләр...» ......................
«Минус утыз...» ........................
Шәһәр баласы мин .......................
«Мин көтмим...» ........................
Соры буын ............................
«Шигырьгә күңел ятмый...» ................
Көз ................................
«Иртәләр салкынайды...» ..................
«Мин ялгыз аучы...» ......................

**Мин сине кыш көне яраттым...**

«Мин сине кыш көнне яраттым...» .............
«Мин акылга яшим буйсынып...» .............
«Йолдыз балкый тәрәз артында...» ............
«Акчарлаклар оча Идел өстендә...» ...........
«Сине күрү белән...» .....................
Җавапсызлык корбаны ...................
«Күңелемдә син уяткан хисләр...» .............
«Мин сине яратам...» .....................
«Мин ул изге затны кабат яраттым...» ..........
Шигъри сурәт ..........................
«Сагындырасың син...» ....................
«Минем хисем...» .......................
«Көям димен...» .........................
«Шигырьләр сәер туа...» ..................
Яңгыр ...............................
Яратам ..............................
«Төннәр буе йолдызларга...» ................
Дөньяның бер матурына ..................
«Сине күреп...» ........................
«Кояш янә сүнде...» .....................
«Мин сине шундый яраттым...» .............
«Төрле тавышлардан да...» .................
Юктырсың ............................
Син һәм мин ...........................
Аның өчен ............................
Кояшкаем ............................
«Минем сиңа бу мизгелдә әйтер сүзем бар...» .....
«Һәр секундын тоеп яшим мин тормышның...» ....
Иң зур сер ............................
Үзең кирәк ............................
«Чыгып киттең...» .......................
«Диңгез идең...» ........................
«Икебез дә ут йотабыз...» ..................
«Күк болыны тузганагы...» .................
«Үптермисең, киптерәсең...» ...............:
«Синең җаннарыңда борчу булса...» ...........
«Сагына белмим икән бит...» ................

«Туңга әйләндереп китте...» .................
«Мин сине эзләдем даладан...» ...............
Яз кочагы .............................
Сафлык ................................
Алданмагыз язга .........................
Йөрәгем... .............................
«Күкләрдән ялварып сорадым...» ..............
«Зәңгәр хыял...» .........................
«Күрәсем килә...» .........................
Күз яме ...............................
«Ярым уяу...» ...........................
«Бәхетем канат кагына...» ...................
«Мин яратам» дию...» ....................
Ник? ................................
«Карашыңнан челтер чишмә ташый...» ..........
«Шырпы булып кабынам да...» ..............
«Тәрәзләргә иртән салкын кояш керде...» ........
Гашыйклар көне .........................
«Мәхәббәт карага буялган...» ................
«Яңгыр сиңа...» ..........................
«Дөньяда мәхәббәт...» .....................
Бәхетсез бәхетле .........................
Бәхет йолдызында ........................

Литературно-художественное издание

**Джамал** Айдар
(**Замалиев** Айдар Маратович)

В ДУШЕ — НЕБЕСА...

Казань. Татарское книжное издательство. 2008

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Җамал** Айдар
(**Җамалиев** Айдар Марат улы)

КҮКРӘГЕМДӘ — КҮКЛӘР...

Мөхәррире *И.Г.Ногманов*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы
*Ф.Р.Гыйсмәтуллина*
Корректоры *Г.Х.Сундукова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 26.05.2008. Форматы 70x90 $^{1}/_{32}$. Шартлы басма табагы 3,51.
Шартлы буяу-оттиск 3,80. Нәшер-хисап табагы 2,2. Тиражы 2000 д. Заказ Т-580.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ. 420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.